КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 май г.Казань № 741

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы коллегиясе санын һәм составын раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1283 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы коллегиясе санын һәм составын раслау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1283 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 гыйнвар, 30 нчы; 2022 ел, 27 гыйнвар, 63 нче; 2022 ел, 19 февраль, 143 нче; 2023 ел, 30 гыйнвар, 75 нче; 2023 ел, 1 март, 194 нче; 2023 ел, 5 сентябрь, 1075 нче; 2025 ел, 30 декабрь, 1222 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «19 кеше» сүзләрен «20 кеше» сүзләренә алмаштырырга;

коллегия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Созинов Алексей Станиславовичны | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисен (килешү буенча); |

Марат Мансур улы Бариевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)»;

Светлана Михайловна Захарованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча)»;

Илдар Флүс улы Миргалимовның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары»;

«Шәрипова Гүзәл Азат кызы» сүзләрен «Нигъмәтуллина-Шәрипова Гүзәл Азат кызы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин